**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮРӘЗМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LIII УТЫРЫШЫ**

**КАРАР № 80**

**Үрәзмәт авылы** **03.02.2025 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә хакында «2020 елның «16» декабрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 2025 елның 22 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә хакында «2020 елның «16» декабрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, сатып-алуларның план-графигы нигезендә төзелә (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелергә тиешле сатып алу очракларыннан тыш), һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Үрәзмәт авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мөслим муниципаль районының
Үрәзмәт авыл җирлеге Башлыгы Ә.Г.Закирҗанов